**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5229**
**12.10.2020**

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль ярдәм күрсәтү хокукын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 6 апрелендәге 1695 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программа чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Халыкны социаль тәэмин итү» 1003 бүлеге буенча каралган акчалар хисабына 72069,63 мең сум: 2020 елда – 24309,06 мең сум; 2021 елда – 23856,28 мең сум; 2022 елда – 23904,29 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел (мең сум) | 2021 ел (мең сум) | 2022 год (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Муниципаль бюджет | 24309,06 | 23856,28 | 23904,29 | 72069,63 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |

- 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурс белән тәэмин итү

2020-2022 елларга программаны финанслау күләме 72069,63 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Чорда барысы 72069,63 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча бүлеп:

2020 ел - 24309,06 мең сум,

2021 ел - 23856,28 мең сум,

2022 ел - 23904,29 мең сум.»;

- 6 бүлектә «Финанслау чыганакларын күрсәтеп финанслау, мең сум» баганасындагы, «2020 (мең сум) графасында»:

13 пунктта «565,97» цифрын «625,97» цифрына алмаштырырга;

2 бурычның «барлыгы» юлында «3019,03» цифрын «3079,03» цифрына алмаштырырга;

14 пунктта «280,0» цифрын «220,0» цифрына алмаштырырга;

3 бурычның «Барлыгы» юлында «1760,03» цифрын «1700,03» цифрына алмаштырырга;

- 6 бүлектә 6 бурычны төшереп калдырырга;

- Барысы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барысы: | | | | 72470 | 73246 | 73246 | 73246 | 24309,06 | 23856,28 | 23904,29 |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов